Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының уналтынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2022 ел № 55

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставының 24.1 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 19 ноябрендәге 146 номерлы карары белән (2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) имзалар кәгазьләре нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карар чыгарды**:

Питрәч авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктлар территориясе өлешендә гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Питрәч авылында Уңыш урамының гражданнар җыенын 2022 елның 12 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Уңыш урамындагы 13 нче йорт янында үткәрергә.

«Сез, 2023 елда Питрәч авыл җирлеге, Питрәч авылы Уңыш урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәр би операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- бистә эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Олан Иле авылында Болын, Пионер, Кояшлы, Үзәк урамнарының гражданнар җыенын 2022 елның 20 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кояшлы урамындагы 7А нче өй., Авокадо кибете янында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда Питрәч авыл җирлеге, Олан Иле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым

кертүгә, 1 төркем инвалидлар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- бистә эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов